# Кушма җөмлә төрләре

# Максат:

1. Кушма җөмлә төрләре турында мәгълүмат бирү;
2.Укучыларның анализ ясау, гомумиләштерү, мөстәкыйль фикерләүләренә ирешү;
3. Укучыларга әхлак тәрбиясе бирү.

# Өй эшен тикшерү

1.Сорауларга җавап бирү:

а) Кушма җөмлә дип нинди җөмлә атала?

б) Ул ничә җөмләдән тора?

2. “Беренче укытучым” дигән темага мини-сочинениеләрне тапшыру.

# Проблемалы ситуация булдыру. Уку мәсьәләсен кую

| ? | |
|---|---|
| Кыңгырау шалтырады, дәрес башланды. | Кыңгырау шалтырагач, дәрес башланды. |

Кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләр нинди чаралар ярдәмендә бәйләнә?

# Дәрескә максат һәм бурычлар кую.
# Дәрес темасын ачыклау

**Кушма җөмлә, бәйләнеш төренә карап, тезмә кушма һәм иярченле кушма җөмләләргә бүленә.**

**Мәсәлән: Алтын черемәс, тимер тузмас.(мәкаль)- тезмә кушма җөмлә**

**Күзләре ачык булса да, ул дөм сукыр иде. (Ә.Еники)- иярченле кушма җөмлә**

**Бәйләүче чаралардан чыгып, кушма җөмлә нинди төрләргә бүленә?**

# Үрнәккә нигезләнеп, тезмә кушма һәм иярченле кушма җөмләләр төзергә:

- Син әйтмәдең, мин ишетмәдем. (тезмә кушма җөмлә);
- Син әйтмәгәнгә, мин ишетмәдем. (иярченле кушма җөмлә);

# “Хәрәм малның хәере юк” текстын сәнгатьле укырга һәм иярченле кушма җөмләне табарга, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чараны күрсәтергә:

Минем абыем, ВДВ да хезмәт итеп кайткач, милициягә эшкә урнашты. Ул көннәр буе машиналар хәрәкәтен күзәтә, юл кагыйдәләрен бозганнарны кисәтә. Араларында акча бирергә теләүчеләр дә була икән. Илфат абый машина йөртүчеләргә хәрәмнең нәрсә икәнлеген җентекләп аңлаткан. Кайберәүләр аны сынап карарга теләгәннәр. Минем абый сынатамы соң? Аның кебек гадел, әдәпле, тәрбияле егетләр күбрәк булса, илдә яшәве күпкә тыныч, рәхәт булыр иде дип уйлыйм. Кешеләргә бу турыда күбрәк аңлатырга кирәк. Юл читенә куелган рекламаларга “Хәрәм малның хәере юк!” дип язарга киңәш итәр идем.

# Өй эше

1. Кагыйдәне өйрәнергә;

2. “Хәрәм малның хәере юк” дигән мәкальне сез ничек аңлыйсыз? Кушма җөмлә төрләрен кулланып языгыз.

**Сез бик акыллы, эшчән, тәрбияле һәм шәфкатьле балалар!**